**КАРАР**

**“16” ноябрь 2019 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 175сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле автомобиль юлларында юл эшчәнлеге алып бару:

- Урта Бирәзә авылында Х.Такташ урамының 75а йортыннан 82 нче йортына кадәр юл- урам челтәренә вак таш җәю;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юлларга ямау ремонты ясау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 163 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 125 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 125 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә Урта Бирәзә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 175сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле автомобиль юлларында юл эшчәнлеге алып бару:

- Урта Бирәзә авылында Х.Такташ урамының 75а йортыннан 82 нче йортына кадәр юл- урам челтәренә вак таш җәю;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юлларга ямау ремонты ясау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ“

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт; ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова